**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ШЫРДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2021 елның 13 июле № 41

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Шырдан авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 ноябрендәге 145 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Шырдан авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 13 апрелендәге 154 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Шырдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Олы Шырдан авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Шырдан авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 ноябрендәге 145 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Шырдан авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (2020 елның 13 апрелендәге 154 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 1.7.1 пунктын киләсе эчтәлек белән тулыландырырга:

1.7.1. Гражданнар җыены торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләре критериеннән чыгып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

1.2. 3.5 пунктта «торак пунктта яшәүчеләр» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлеше)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә, шулай ук Яшел Үзән муниципаль районы Олы Шырдан авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Олы Шырдан авылы, Г.Тукай урамы, 10 нче йорт (җирлек администрациясе бинасы), Олы Шырдан авылы, Киров урамы, 6 нче йорт (мәдәният йорты бинасы).

**Олы Шырдан авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Р.Р. Кэримов**